СОВЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода,
422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский Бистәсе авылы,
422591

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

РЕШЕНИЕ — КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

12.02.2024 с. Введенская Слобода №33-287

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советының «Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә җир салымын билгеләү турында» 2005 елның 17 ноябрендәге 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31нче бүлегенә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә җир салымын билгеләү турында» 2005 елның 17 ноябрендәге 14 номерлы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарның 5 статьясындагы 3 пунктының икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Гольф яки ат йөрүләре өчен басу өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 0,3% түбәнәйтелгән салым ставкасын куллану рәвешендә җир салымын түләүгә ташлама бирергә (гольф уены өчен урыннар булдыру яисә ат йөрүләрен гамәлгә ашыру, шул исәптән кирәкле җир эшләрен башкару һәм ярдәмче корылмалар урнаштыру, трибуналар урнаштыруны күздә тотмаган ат-спорт манежлары урнаштыру)».

«Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә җир салымын билгеләү турында» Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советы карарының текстын яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

3. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Бу карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Введенский Бистәсе авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов

Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советының 2024 елның 12 февралендәге 33-287 номерлы карарына

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә җир салымын билгеләү турында

Статья 1. Гомуми нигезләмәләр

Россия Федерациясе Салым кодексының 31нче бүлеге нигезендә, әлеге карар белән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле җир салымы (алга таба – салым) билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.

Статья 2. Салым ставкалары

Салым ставкалары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

1. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә кертелгән җир кишәрлекләренә карата торак пунктларда авыл хуҗалыгы куллану зоналары составында һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җирләргә карата 0,3 %;

2. Торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) 0,3 %;

3. Эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук "Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2017нче елның 29нчы июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата 0,3%;

4. Оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,3 %;

5. Башка җир кишәрлекләренә карата 1,5 %.

Статья 3. Хисап чоры

Салым түләүче оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы таныла.

Статья 4. Салым түләү тәртибе һәм сроклары

Салым түләүче оешмалар тарафыннан үткән салым чорыннан соң килүче елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча салым түләнергә тиеш. Салым буенча авария түләүләре салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан узган хисап чорыннан соң килә торган айның 28 числосыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш.

Статья 5. Салым ташламалары

Салым салудан азат итергә:

1. Гражданнар күмү белән шөгыльләнүче җир кишәрлекләренә карата оешмалар һәм учреждениеләр

2. Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлары, Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм сугышында катнашучыларның тол хатыннарының (толларының), 4 һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган салым түләүче физик затлар;

3. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләренә карата, су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү объектлары биләгән җир кишәрлекләренә, гомуми файдаланудагы мәйданнарга, урамнарга, юлларга, паркларга, аллеяларга, яшел утыртмаларга, һәйкәлләргә, бәйрәм чараларын уздыру урыннарына һәм гомуми файдаланудагы башка объектларга карата оешмалар һәм учреждениеләр.

Гольф яки ат йөрүләре өчен басу өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 0,3% түбәнәйтелгән салым ставкасын куллану рәвешендә җир салымын түләүгә ташлама бирергә (гольф уены өчен урыннар булдыру яисә ат йөрүләрен гамәлгә ашыру, шул исәптән кирәкле җир эшләрен башкару һәм ярдәмче корылмалар урнаштыру, трибуналар урнаштыруны күздә тотмаган ат-спорт манежлары урнаштыру).

Җирле бюджеттан финанслана торган бюджет учреждениеләре биләгән җир кишәрлекләренә карата салымның киметелгән ставкасын 0,6% куллану рәвешендә җир салымын түләү буенча ташламаны, әлеге карарның 2нче статьясындагы 1, 2, 3, 4нче пунктларында каралган җир кишәрлекләреннән тыш, бирергә.

Гомуми файдаланудагы 1-3 категориядәге автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата җир салымын түләүгә ташлама бирергә, салымның киметелгән ставкасын куллану рәвешендә , 0,05 %.

Бюджет учреждениеләре тарафыннан республика һәм федераль бюджетлардан финанслана торган җир кишәрлекләренә карата, әлеге карарның 2нче статьясындагы 1, 2, 3, 4нче пунктларында каралган җир кишәрлекләреннән тыш, салымның киметелгән ставкасын 1% куллану рәвешендә җир салымын түләү буенча ташлама бирергә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов